ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

14 апрель 2020 ел

**КАРАР**

№ 1826

Башкарма комитетның «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 20 сентябрендәге 5735 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 20 сентябрендәге 5735 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3276 номерлы, 2018 елның 25 апрелендәге 2307 номерлы, 2018 елның 5 июнендәге 3223 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6591 номерлы, 2019 елның 20 мартындагы 1375 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 3046 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «2014-2021 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

2) «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

- 1.4 пунктта 5, 6 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы», 11.10.2019, № 76, ст. 2098);

6) «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында Яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләре, «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасына 3 нче кушымта («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы», 11.10.2019, № 76, ст. 2098) (алга таба – Кагыйдәләр);»

- 2.1 пунктта:

«2016-2021 елларга» сүзләрен «2020-2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга»;

«2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы» сүзләрен «2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.5 пунктта:

16 пунктчада «хезмәт кенәгәсенең күчермәсе» сүзләрен «хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яки кәгазьдә тиешенчә расланган яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эш бирүчедә булганда) белән имзаланган электрон документ рәвешендә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләренә алмаштырырга;

«2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы» сүзләрен «2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.8 пунктта «2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы» сүзләрен «2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.9 пунктта «2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы» сүзләрен «2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

- 1 нче кушымтада «2014-2021 елларга» сүзләрен «2020-2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 нче кушымтада «2014-2021 елларга» сүзләрен «2020-2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

- 3 нче кушымтада «2014-2021 елларга» сүзләрен «2020-2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов